# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

11 март 2025 ел № 690

**«Торак урынны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру эшләрен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 25 августындагы 2357 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә Башкарма комитет

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Торак урынны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру эшләрен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 25 августындагы 2357 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йортта урынны үзгәртеп планлаштыру мондый бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән һәм (яисә) яңа биналар булдырудан, шул исәптән әлеге Кодексның 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яки) аның эчке планлаштыруын үзгәртүдән (шул исәптән бинаның чикләрен һәм (яки) мәйданын үзгәртмичә) гыйбарәт. Бинаны яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә чиктәш биналарның чикләре һәм (яки) мәйданы да үзгәртелергә мөмкин. Яңадан планлаштыру бинаның (урыннарның) чикләре һәм (яки) мәйданы турында бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә үзгәрешләр кертү яисә төзелгән биналарны дәүләт кадастр исәбенә алу һәм төзелгән биналарга хокукны дәүләт теркәвенә алу кирәклегенә китерә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев